КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 5 декабрь г.Казань № 1561

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бөртекле культуралар җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 836 нчы карары белән расланган Бөртекле культуралар җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бөртекле культуралар җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бөртекле культуралар җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 836 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 27 июнь, 608 нче; 2022 ел, 21 октябрь, 1130 нчы; 2022 ел, 11 ноябрь, 1204 нче; 2023 ел, 20 март, 279 нчы; 2023 ел, 29 май, 649 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Бөртекле культуралар җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бөртекле культуралар җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның икенче абзацында «башка бюджетара трансфетлар» сүзләре алдына «, шул исәптән финанс белән тәэмин итү чыганагы – Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган» сүзләрен өстәргә;

8 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявка бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага карата салым органы тарафыннан бирелгән салым түләүченең (җыюны түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү бурычлары үтәлүе турында белешмә кәгазе (сайлап алуда катнашучы тарафыннан мондый документ тапшырылмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);»;

җиденче абзацта «агымдагы елның 1 гыйнварыннан 28 февраленә кадәр» сүзләреннән соң «, һәм (яки) агымдагы елның 1 августыннан 30 сентябренә кадәр» сүзләрен өстәргә;

14 пунктта:

алтынчы абзацта «агымдагы елның 1 гыйнварыннан 28 февраленә кадәр» сүзләреннән соң «, һәм (яки) агымдагы елның 1 августыннан 30 сентябренә кадәр» сүзләрен өстәргә;

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әгәр җитештерү һәм сату чыгымнарының бер өлешен каплау максатларында субсидия бирелә торган билгеле бер бөртекле культура җитештергәндә мондый бөртекле культураның уңышын югалту (юкка чыгу) рискына бәйле мөлкәт характерындагы мәнфәгатьләргә дәүләт ярдәме күрсәтеп, авыл хуҗалыгы иминләштерелмәгән булса, субсидия күләмен исәпләп чыгарганда 0,7 коэффициенты кулланыла;»;

уналтынчы абзацта «агымдагы елның 1 гыйнварыннан 28 февраленә кадәр» сүзләреннән соң «, һәм (яки) агымдагы елның 1 августыннан 30 сентябренә кадәр» сүзләрен өстәргә;

15 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «агымдагы елның 1 гыйнварыннан 28 февраленә кадәр» сүзләреннән соң «, һәм (яки) агымдагы елның 1 августыннан 30 сентябренә кадәр» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацта татар текстында «агымдагы елның 1 гыйнварыннан 28 февраленә кадәр» сүзләреннән соң «, һәм (яки) агымдагы елның 1 августыннан 30 сентябренә кадәр» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин